ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 ноябрь 2020 ел № 5739

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5951 номерлы карары белән расланган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5951 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3271 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 3597 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6597 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 6497 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынга мохтаҗлар буларак исәпкә кую өчен:

1) гариза (1 нче кушымта);

2) гариза бирүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт яки шәхесне ачыклаучы башка докуметларының күчермәләре;

3) гариза бирүче гражданның гаилә составы турында документларының күчермәләре (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.);

4) гражданның федераль бюджет акчалары хисабына торак урын белән тәэмин ителүгә хокукын раслаучы документ;

5) 1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашыра торган дәүләт теркәве органыннан гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек

хокукында торак урыннары булу яки булмау турында гариза бирүче гаиләсенең һәр әгъзасы тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар;

6) гариза бирүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар күчермәләре (1999 елның 31 декабренә кадәр);

7) вәкилнең вәкаләтен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән аның вәкиле эш иткәндә).

Торак сатып алуга Дәүләт торак сертификаты алу өчен:

1) планлаштыру елында сертификат бирү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә гариза;

2) «Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм комфортлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасында катнашучылар составына кертелү турында гариза (рапорт) (2 нче кушымта);

3) Дәүләт торак сертификаты бирү турында гариза (рапорт) (3 нче кушымта);

4) гариза бирүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт яки шәхесне ачыклаучы башка документларының күчермәләре:

5) торак урынның өстәмә мәйданын алуга хокукны раслаучы документ күчермәсе (андый хокук Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда);

6) вәкилнең вәкаләтен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткәндә)»;

7) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасының күчеп китәргә мәҗбүр булганнар статусындагы таныклыгы күчермәсе;

8) даими яшәү өчен торак урын, торак урын төзүгә (сатып алуга) ссуда яки социаль түләү яисә югалткан торак урын өчен компенсация алу (алмау) турында миграция өлкәсендә контроль органыннан белешмә»;

2) 2.6 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

4) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүмат;

5) гариза бирүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслаучы документларның күчермәләре (2000 елның 1 гыйнварыннан);

6) торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урында яшәгән очракта)»;

3) 3.3.2. пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тапшырылган документлар исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара запрослар буенча алыначак документлар исемлеген күрсәтеп, аларның описьларын гариза бирүчегә тапшыру.»;

4) 3.4.1. пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Район хакимияте белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кирәкле мәгълүмат бирү турында запрослар җибәрә.»;

5) 3.5.13. пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов